# Эколого-математик брейн –ринг.

Учитель математики Гайфуллина Ф.Р.

**Балыкка – су, кошка – һава, җәнлекләргә – урман-кырлар,кешегә - Туган җире кирәк..**



Кайчандыр бик матур булган җиребез бүген бик аяныч хәлдә. Җир,һава, суның һәрвакыт пычранып торуы кешелек дөньясын котылгысыз катастрофага этәрә.



# Шуңа күрә дә бүгенге математик ярышыбызны экологик проблебаларга багышладык

- Уенда 2 команда катнаша.Кайсы команда алдан кул күтәрә,шул җавап бирә. Җавап ялгыш булса, сүз икенче командага бирелә.Дөрес җавап-1 балл.
- Командаларның җаваплары дөрес булмаса ,уенга тамашачылар кушыла һәм дөрес җавапларын үзләре теләгән командага бирәләр.

# Раунд1

1.Җиргә ташланган банан кабыгы 2 елда гына череп бетә.Ә тәмәке төпчеге 2 елга артыграк. Пластик пакет , төпчеккә караганда 8 елга артыграк таркала.Пластик пакет ничә елда таркалып бетә? Банан кабыгы пластик пакеттан ничә елга алданрак таркалып бетә?



Җавап:12 ел,  10ел

# Раунд 1



- 2: Дөньяда ел саен1600 млн.куб. м агач житештерелә, шуның биштән бер өлеше ягулыкка китә. Ел саен ничә куб метр агач ягулыкка китә?

: 320 млн. куб.м.

# Раунд1



- 3. Кешеләрнең уртача гомере 64 ел.Бу уртача гомернең x елын (5x+30=50) кешеләр медицина ярдәмендә яши . Врачлар кеше гомерен ничә елга озынайта?

Җавап: 4 ел.

# Раунд 1


- 4. 1 тонна нефть 12 м$^2$ океан өслеген юка пленка белән каплый.. Бер ел эчендә диңгез һәм океаннарга 10 млн. тонна нефть ага.Бер ел эчендә диңгез, океаннарның ничә квадрат метры нефть белән каплана?
- 120 млн.кв.м



# Нәрсә артык?







- Әйе,укучылар, дәрес әйттегез.Сезнең тормышыгызда тәмәке һәрвакыт артык,кирәкмәгән әйбер булып калсын иде. Сез беләсезме соң? Тәмәкенең 1-2 пачкасында кешене үтерерлек дозада никотин була. Тәмәке тартучы бер пачканы берьюлы тартып бетермәгәнлектән генә исән кала.


50 лет
45 лет
40 лет
35 лет
30 лет
25 лет
20 лет
Мера жизни?..
НЭТИ
НГТУ

# Раунд 2

1.Су- табигый байлык ул.Аннан башка җирдә тереклек булмас иде.Су шулай ук кеше,хайваннар һәм үсемлекләр организмының состав өлеше дә. Организмда матдә һәм энергия алмашы су булганда гына бара.Бер кешегә 70 яшьә кадәр яшәү өчен 50 т чамасы су кирәк.Безнең мәктәп укучыларына(32 бала) шулкадәр яшәү өчен күпме су кирәк булыр?

# Раунд 2



- 2. Промышленность алга киткән шәһәрләрдә һәр кешегә 25 квадрат метр яшеллек туры килергә тиеш. 470000 кешесе булган шәһәрдә яшеллек утыртылган мәйдан ничә кв. м. булырга тиеш?

Җавап: 11750000 кв. м.

# Раунд 2

- 3. Барыбыз да беләә, чиста суның запасы чиксез түгел. Әгәр краннан карандаш калынлыгында гына су акса да,1 минутта 3л су агып китә.15 минутта 3 краннан ничә л су агар ?

Җавап : 135 л.



# Раунд2

4. Үзенең үсеш чорында 1 златоглазка личинкасы 1130 га якын үсемлек бетен юк итә. 15820 үсемлек бетен бетерү өчен ничә златоглазка личинкасы кирәк ?



# Раунд 3

- 1. Бер илдә ашамлыклар тутыру өчен пенопласт тартмалар куллануны тыйганнар, чөнки алар зыянлы.Хәзер анда ашамыкларны кәгазь тартмаларга тутыралар.Кайсы ил соң ул? Шифровка ярдәмендә ачыкла. И 8*15*125 ; А 252: x=21; К 50*75*2;

Т (x-12)*8=56 ; Й 575 : 23




Ж

| 7500 | 15000 | 19 | 12 | 25 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

# Раунд 3

- 2. Каштанның 100 г яфрагы 15 көндә 2286 г тузан йота.30 көндә 300г каштан яфрагы күпме тузан йота ?

Ответ:13716 г.



# Раунд 3



3).1т кәгазь ясау өчен 17 агач кирәк. 510 агачны саклап калу өчен күпме макулатура җыярга кирәк?

Җавап: 30т.

# Раунд 3

4 . 22 апрельә барлык илләрдә дә Җир көнен бәйрәм итәләр.Бу көнне бөтен дөнья халкы Җиребезне, гүзәл табигатебезне саклау турында уйлана. Үзенең кулыннан килгән кадәр эшләр башкара.? Ә безниләр эшли алабыз соң?Һәр дөрес җавап 1 балл.



- Әйе,укучылар, Җирнең яме, авылыбызның яме безнең кулларда

- Әзербайҗан шагыйре С.Вургунның акыллы сүзләрен истә тотсак, бер генә яфракны яки чәчәкне өзмичә дә табигать белән аралашудан зур канәгатьләнү алырга мөмкин бит.

- Сәхраларда сәер кылыйк әле
- Хозурланып,икәү бергәләп
- Чәчәкләрне сөеп, иркәләп.
- Мин иелер идем һәр чәчәккә
- Өзәр өчен түгел,кызганмыйча шуны өземме?
- Багар идем аның нурлы йөзен,
- Күрсен иде чәчәк үземне.

